

2025  елнын 19 апрелендә Республика Главасы Артём Здунов житәкчелегендәге Мордовия делегациясенен Херсон олкәсенә эш сәфәре кысаларында тобәк губернаторы Владимир Сальдо белән очрашу vтте. Мордовия һәм Херсон  олкәсенен vзара хезмәттәшлеге турында фикер алыштылар.
Мордовия  делегациясе составына республика Главасы администрациясе, Хокvмәтнен социаль блогы, стратегик инициативалар Агентлыгы, Бизнес, мәдәният һәм  спорт жәмәгатьчелеге вәкилләре кергән. Исегезгә тошерәбез, хезмәттәшлек  турындагы килешv кысаларында Мордовия Херсон олкәсенен Каланчак округына инфраструктураны торгызуда, тыныч тормышны жайга салуда ярдәм кvрсәтә.

Мордовия белгечләре торак-коммуналь хужалык, социаль олкә объектларында эшлиләр. Округ территориясендә коммуналь инфраструктура объектларында аварияләрне һәм аларнын нәтижәләрен бетерv очен авария-торгызу бригадасы  даими эшли. Республикабыз, авария хәлләрен кисәтv очен, матди-техник  ресурслар резервын формалаштыруда ярдәм итә.
Подшефный Каланчакка  даими рәвештә Мордовия табиблар бригадалары составындагы педиатрлар,  хирурглар, неврологлар, гинекологлар, лаборантлар, тар профильле  белгечләр барып эшлиләр. Жирле vзәк район хастаханәсендә округ халкына  операцияләр, диспансеризация һәм вакцинация vткәрәләр. Узган ел эчендә  генә дә Мордовия табиблары 25 меннән артык тикшерv һәм консультацияләр  уздырган. Шуларнын 5 мене – балалар, 6 меннән артыгы – хирургия  профилендәге пациентлар.
Республикабыз  Каланчак медицина  учреждениеләренә медицина жиһазлары һәм медицина препаратлары белән  булыша.
Остенлекле юнәлеш - балалар. “Жәйге һәм кышкы сәламәтләндерv  кампанияләре чорында балаларны рес-публикабызга чакыруны дәвам итәбез.  Без аларны котәбез, сәламәтләндерv лагерьлары һәм мәдәни программалар  әзерлибез”, - диде Артём Здунов.
Херсон олкәсе губернаторы Мордовия  Главасына республиканын Каланчак округына кvрсәткән ярдәме очен рәхмәт  белдерде. “Ин моһиме, бiредә яшәvче кешеләр Россиягә кайткач, туган  гаиләләренә кайтканнарын анлыйлар”, - диде ул.
Артём Здунов белән  Владимир Сальдо Мордовия Республикасы, Херсон олкәсе һәм стратегик  инициативалар Агентлыгы арасында киләчәк багланышлар мәсьәләләре буенча  кинәшмә уздырдылар. Исегезгә тошерәбез, 2024 елнын декабрендә безнен тобәкләр һәм стратегик инициативалар Агентлыгы арасында Херсон олкәсенен  социаль олкәсен vстерvгә юнәлдерелгән социаль-гуманитар проектларны  гамәлгә ашыру турында килешv тозелгән иде. Бу, барыннан да элек, тәжрибә  уртак-лашу, шулай ук сәламәтлек саклау, социаль яклау һәм мәгариф  олкәсендәге бурычларны хәл итv очен ин яхшы тәжрибәләр кертv буенча  уртак эш.

Артём Здунов билгеләп vткәнчә, Милли социаль инициатива кысаларында, Стратегик инициативалар агентлыгы белән берлектә, Мордовиядә инде оченче ел Тобәк социаль стандарты, Сервис вәкилләре институты кертелә. Бу социаль блокнын «Сәламәтлек саклау», «Мәгариф», «Социаль яклау», «Хезмәт базары һәм мәшгульлеккә ярдәм» кебек барлык юнәлешләре буенча кешегә vзәкләштерелгән якын килvләрне кертvгә остәмә этәргеч бирә.
Мордовия Республикасынын Региональ сервис вәкаләтлесе методик ярдәме белән Херсон олкәсендә берничә проектны гамәлгә ашыру планлаштырылган. Аерым алганда, Геническ шәһәренен «Патриот «Яшьләр vзәге» базасында «Нечкә материя – яшvсмерләр очен навигатор» практикасы кертеләчәк - ул яшvсмерләргә vз-vзләрен белдерv очен куркынычсыз пространствоны оештыруга юнәлдерелгән.